МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_____20.09.2024____________ Казан ш. № ____671________

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымтага үзгәреш кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.03.2023 ел, №180, 23.04.2024 ел, №316, 25.07.2024 ел, №527 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны

эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымтага, үзгәреш кертеп, түбәндәге эчтәлекле 12, 13 пунктларын өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «12 | «Инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм» региональ чаралар комплексы чараларын гамәлгә ашыру | «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында «Инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм» региональ чаралар комплексы чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | P = M1 x S1 + M2 x S2 + Mn x Sn,<br>биредә:<br>P - субсидия күләме;<br>M1, м2, Mп - «Инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм» региональ чаралар комплексы нигезендә тиешле чаралар S1, S2, Sn – чараның бәясе |
| 13 | Балаларның иминлеген тәэмин итүнең региональ системасын үстерү буенча чаралар комплексы чараларын гамәлгә ашыру | «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм» дәүләт программасы кысаларында балаларның иминлеген тәэмин итүнең региональ системасын үстерү буенча чаралар комплексы чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру | P = M1 x S1 + M2 x S2 + Mn x Sn,<br>биредә:<br>P - субсидия күләме;<br>M1, M2, Mп - балаларның иминлеген тәэмин итүнең региональ системасын үстерү буенча чаралар комплексы нигезендә тиешле чаралар;<br>S1, S2, Sn - чараның бәясе.». |

2. Әлеге боерык 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова